
Көлү – сихәт, көлеп яшәү мәслихәт!

ISSN 0136-7110


Чаян



САТИРА ҺӘМ ЮМОР ЖУРНАЛЫ АПРЕЛЬ * 2025 * КАЗАН

4





Михаил ЛАРИЧЕВ

Марсель ГАЛИЕВ

ДӘҺШӘТЛЕ ЧИБӘРЛЕК

Кәттә атлап килә!
Нәзакәтле бармаклары арасында
Җем-җем көйри сигаретның көлсу күзе.
Кызыл-кучкыл иреннәрдән, бөдрәләтеп,
Божра-божра төтен чөеп килә үзе.
Көмеш ука – зәһәр озын тырнаклары,
Колагында – киергедәй алкалары.
Ничә илнең байрак төсе – чәчләрендә,
Сокланыйммы бу замана чәчәгенә?!
Бар да кебек, юк та кебек – кыска итәк,
Көязлекнең тантанасы – чая ботлар,
Чыкы-чыкы чукып бара үкчәләре,
Хәтта туктап, тынын көйли чал ир-атлар.
Калку-текә күкрәгенең ядрәләре
Тетрәп тора муенсалар арасыннан.
Сискәнер дә кояш нуры кире чигәр
Назы качкан тәкәббер боз карашыннан.
«Шоу» дигән шау, иблис көе – металл шаңы
Яшьлегеннән эчке моңын савып алган.
Узган гасыр комсомолы – әбисеннән
Татарлыгы бер әчмуха йогып калган.
Чибәр үзе, каһәр!
Мондый килеш-килбәт
Халыкара модаларны тез чүктерә.
Асылында – нинди фасыл?..
Сүз камчысын
Селти язып тыелалдым чүт-чүт кенә.
Яшь әнкә бу!
Парк буйлап этеп бара –
Фаэтондай купшы-матур баларбасы.
Хакыйкатькә күзеңне ач, менә нинди –
Милләтеңнең сөтен җуйган чор анасы...

* * *

Шакып уятты да...
Хатирәләр купты тамырыннан.
Әнә ул – мин, ята сабый, күккә карап,
Имезлеге – арыш камырыннан.
Кабык арба тартып әнкә бара
Рәшәле басу камылыннан.
Кинәнәме тургай, нинди моңнар саркый,
Талир тәңкә чыңы – толымыннан.
Елату да шуннан, юату да шуннан –
Буыннардан күчкән үз моңыннан.
Әнкә сөте белән, үлән суты белән
Ыгып, ялантәпи җилдергәнбез!
Туган телдән тәлгәш-тәлгәш сүзләр өзеп,
Тәм-сихәтен җанга сеңдергәнбез.
Тынма, хәтер... Йодрыклана үҗәтлегем:
Искермәгән әле иске көйләр!..
Бәхилләшә кырыс заман арьягыннан
Айлы алка таккан чын әниләр.
Җырда гына калган инәкәйләр...

* * *

Үтеп китте әнә!
Чәнти бармак белән
Этеп кенә затлы баларбасын.
Үткен тояк – биек үкчә, чыкы-чыкы,
Узып бара, чәнчеп... үз алласын...





ШОМБАЙ болай диде...



Хөрмәтле «Чаян»! Нинди генә курслар, марафоннар, пирамидалар юк хәзер! Һәм барысында да ничек тиз итеп баерга өйрәтәләр. Шунысы кызык: акчаны көрәк белән көрәргә өйрәтүче мөгаллимнәр үзләре бик күңелсез урыннарга барып эләгә...

Л. ИСЛАМОВ

ТҮБӘН КАМА

– Акчаны көрәк белән көри башлар өчен, башта тырмага басмаска өйрәнергә кирәк! – диде Шомбай ага, укучыбызның хатын укып чыккач.

Рөстәм ЗАРИПОВ

ИКЕ ФИКЕР

КИҢӘШ


Күз алдыңа китер: әйтик, син шыр надан, ә математикадан, гомумән, бум-бум. Һәм кулыңнан өч тиенлек тә эш килми, такылдарга яратасың, телең озын... Димәк, тел белгечелегенә укып чык та, яула берәр редакция урындыгын. Асрамадагы гәҗитләр һәм журналлар андыйларны якын күреп, бирә урын...

"Дуңгызчылык – табышлы тармак" рухында сырла саллы очерклар, мәкаләләр; ялагайлан, әнә текә түрәләр дә тик тук башак баш ия, дип акланалар... Авылым, дип, әнием, дип шигырьләр яз, аннары поэма, повесть, романга күч. Аларны беркем укымый, дип гарьләнмә, асрамадагы басмага шундыйлар төс...

Балет өчен яз аңлатма (либретто) ахыр чутта, андыйга да миллионнар тама бүген... Плагиатта тотсалар, җавап шушы:

– Адәм баласы хатадан хали түгел...





Александр АЛЁШИН



Сергей КОКАРЕВ

Мәкерле агулаучы

Ни дисәң дә, борынгы бабаларыбыз безгә караганда купкә җиңелрәк яшәгән. Үзеңә ошаган тау куышын сайлап аласың, керә торган тишеккә хайван тиресе асып куясың, ут кабызасың да – кызган учакта мамонт ите кыздырып ашыйсың! Ә хәзерге таш калада көн күрүче кеше болай яшәүнең нәрсә икәнен күптән онытты, һәм үзенең юлында теләсә нинди тыныч тормышны агуларлык киртәләр корып куйды. Агулау дигәннән, моны туры мәгънәдә дә аңларга була.

Мәсәлән, Лениногорскида Яңа ел бәйрәмнәрен ир белән хатынга хастаханә койкаларында каршыларга туры килгән. Яшь гаиләне Кошевой урамындагы йорттан газ белән агуланганнан соң китергәннәр. Моның сәбәбе – өр-яңа пластик тәрәзәләрне шыплап ябып, газ колонкасын яндырып кую. Агач тугандашларыннан аермалы буларак, полимер рамалар "суламый" – газны да, һаваны да үткәрми. Шуңа күрә ир белән хатынның да суларга мөмкинлекләре булмаган. Нәтиҗәдә, аларны реанимациядә аңга китерергә туры килгән.

Ә менә Бөгелмәдә аналы-уллы башка сәбәп белән эләккән. Аларның Бауман урамында урнашкан йортларында су җылыткычының һава суырту торбасы тишек булып чыккан. Нәтиҗәсе – агулану һәм газ колонкасын ремонт өчен өзеп кую.

Соңгы "газ атакалары"ның берсе Казанда, Мусин урамының 53 А номерлы йортында булган. Хуҗабикә рәхәтләнеп ванна кергән. Бу процедура аның өчен чак кына соңгысы булмыйча калган. Чыгып яткан газдан аңын югалткан ханымны ашыгыч ярдәм табиблары коткарып калган. Тикшерү эшләре тәмамланганчы, газ тәэмин итүне бөтен подъездда туктатып торырга туры килгән.

Татарстанда бу елның ике ае эчендә илледән артык мондый очрак теркәлгән. Кырык кеше зыян күргән. Сәбәбе йорт хуҗаларының үзләрендә булып чыккан. Билгеле булганча, кайбер фатир хуҗалары планировкадан риза түгел. Кемгәдер бәдрәф бүлмәсе белән ваннаның аерым булуы ошамый, кемнеңдер кухня белән кунак бүлмәсе арасындагы стена күңеленә хуш килми, кемнеңдер башка нәрсәләргә эче поша... Ояларын "затлыландыру" максатыннан, хуҗалар аларны үзләре теләгәнчә үзгәртәләр. Эшнең рәтен белмәгән килеш, үз белдекләре белән газда эшли торган су җылыткычлары куялар, вентиляция системасын үзгәртәләр. Һәм бу башбаштаклыкның агулану, хәтта җитди күңелсезлекләр дә китереп чыгарырга мөмкин булуы турында һич уйламыйлар.


Уйлап карасаң, хәзерге кирпеч-таш пулат хуҗалары үзләрен ерак гасыр бабаларыннан да гамьсезрәк тота булып чыга. Алар йорт учагын беркайчан да караусыз калдырмаган. Гомо сапиенс яктылык һәм җылы чыганагы белән саксыз эш итүнең нәрсәгә китерүен аңлаган. Шуңа күрә дә дөньяның кырыс заманнарында ул исән калгандыр да...

Артём СУББОТКИН



Александр **ШУЛЬПИНОВ**







• • •

Валюта курсын күрсәтә торган табло – соңгы бәйсез СМИ (Средства массовой информации). Массакүләм мәгълүмат чарасы – ул илебездәге икътисадның хәлен аңлата торган басма.

• • •

Ни өчен "лаеклы хезмәт хакы" дип язганда төгәл әйтмиләр, ул бит көлкегә һәм кызгануга лаеклы түләү?

• • •

Мэрия бинасы каршындагы күгәрченнәрне ашатмыйлар, бары тик ашатырга вәгъдә генә бирәләр.

• • •

Авыру табибына уңышлы дәвалаганы өчен, рәхмәт йөзеннән, бүләкләр алып килә. Портфелен ача да төрле кыйммәтле консервлар, коньяклар, кофе, колбасалар чыгара башлый.

Табиб ачуланып:

– Сез нишләп минем акчаны юкбарга әрәм итәсез? – ди.

• • •

– Ял көннәрендә утырып торырга да туры килмәде.

– Нигә?

– Чөнки гел ятып үтте вакытым.

• • •

– Ышаныч калдыр, һәрчак монда керүче.

– Гафу итегез, сез нәрсәдер әйттегез?

– Мин әйтәм: "Рәхим итегез, безнең түләүсез дәваханәгә!"

• • •

– Мин эчмәдем, тартмадым, күп ашамадым, сулга йөрмәдем...

– Аңламыйм, син мактанасыңмы, әллә зарланасыңмы?

• • •

– Кызлар, сез шундый зифа. Мөгаен, диетада утырасыздыр?

– Мин зарплатада.

– Ә мин ипотекада.

• • •

– Бу кабинетта безнең хастаханәнең иң гадел докторы эшли. Ул беркайчан да авырулардан взятка алмый. Ул хәтта коньяк та сорамый. Ул – патологоанатом.

• • •

Тиздән китап тышларына "Нейросетив текстлары юк" дип язачаклар, "100% кеше кулы белән язылган" диеләчәк.



ЮЛ МИЛЛИОНЕРЛАРЫ

Чаллыда "Юл хәрәкәте иминлеге" дәүләт учреждениесенең алты хезмәткәре суд каршына басачак. Берничә ел дәвамында алар тикшермәгән килеш йөк машиналарын үткәреп торганнар, ә йөге артык булган очракта беркетмә төземәгәннәр. Һәрбер шундый очрак өчен алар 500 сум алып барып, 8 миллион сумга баеганнар. "Эшмәкәрләр"нең язмышын суд хәл итәчәк.

ЧИТТӘН ТОРЫП ДӘВАЛАУ

Базарлы Матак үзәк хастаханәсендә "үле" пациентлар тапканнар. Документлар буенча, табиблар Әлки районының 13 кешесен дәвалаганнар, ә чынлыкта исә алар бернинди дә медицина ярдәме алмаганнар, докторларны күрмәгәннәр дә, ә үз "авыру"лары турында берни белмәгәннәр. Анның каравы, хастаханә иминият компаниясеннән даими түләүләр алып барган. Читтән торып дәвалау могҗизасы белән прокуратура кызыксына башлаган һәм инде җинаять эше кузгаткан.

БУРЫЧКА ЯШӘҮЧЕЛӘР

2024 елда Татарстан ил регионнары арасында халыкны кредитлану дәрәҗәсе буенча 74 нче урын алган – бу рейтингта урын никадәр түбәнрәк булса, кредитлану дәрәҗәсе шулкадәр югарырак. Республикада бурычка яшәүчеләрнең уртача бурычы 53,3 мең сум тәшкил итә. Кредитларны капларга керемнең 70,5 проценты китә, ә бу исә ил буенча күсәткечтән 20 процентка күбрәк.

ДӘРТЕ СҮНГӘН

Круглое Поле бистәсендә яшәүче берәү бизнес ачып җибәрмәк булган. 26 яшьлек егет социаль яклау бүлегенә мөрәҗәгать иткән, үзенең чыгып йөри торган автосервис оештыру буенча бизнес-планын тәкъдим иткән һәм җиһазлар сатып алу өчен субсидия сораган. Яшь бизнесменга 350 мең сум биргәннәр. Әмма кулына акча төшү белән, коммерсантның дәрте сүнгән, һәм ул бөтен акчаны шәхси мәнфәгатьләренә тотып бетергән. Чак кына бизнесмен булмый калган ирегеткә хәзер алган акчаны кайтару гына түгел, ә мошенничество статьясы буенча рәшәткә артына утырырга туры килмәгәе.



Александр БРЮХАНОВ

ДӨНЬЯ – КУЛАСА

Безнең җәмгыять, ләкин чикләнгән җаваплылыклы...

Бераз җаваплылыгы бар инде, ләкин аны кем үз өстенә ала, аңлашылмый...

Ул нәкъ үзәктә урнашкан, әмма җимерелеп беткән аерым йортта...

Ленин урамында тора, нигәдер андагы коммунистларны берәү дә якламый...

Берәү дә эшләми анда, тик эшкә йөрүче бар...

Эшләмәсәләр дә, керем килә...

Отчёт документлары да тутырыла, әмма аларны шундук юкка чыгаралар...

Директоры бар, тик ул килешенеп эшләүче генә...

Бик шәп машинада йөри, тик үткән гасырдагы шәп машинада...


Өендә кайнар су булмаганлыктан, мунчага йөрим, ди...

Һәр атна саен хатынын алмаштыра, сәбәбен аңлата берничек тә әйбәтен сайлап таба алмыйм – хатын-кыз хәзер әллә нинди, ди...


Күпләр аны миллиардер, ди, югыйсә хезмәт хакы башкаларныкы кебек...

Күренеп тора: алар барысы да үзе өчен эшли, ә әйтүләренә караганда, Ватан көчен ныгыталар...

Алардан нишләп сез шулай дисез, дип сорыйлар ә алар "Дөнья куласа – әйләнә дә бер баса", диләр.







• • •

Карга, томшыгына сыйр эләктереп, агач ботагында утыра. Төлке, килеп, мәсәлдәге матур сүзләрен сөйли башлый. Карга тыңлап-тыңлап тора да, сыйрын канаты астына кыстырып, "карр", дип җавап бирә.

– Мәсәлне дә үзгәрткәннәр, – дип куя Төлке, авыр сулап.





• • •

– Без, атлар, – ди бер ат ишәккә, – кешенең дуслары арасында иң игелекле кавем. Без кешеләрнең хезмәтләрен җиңеләйтәбез, тормышларын бизибез, сугышта да без алыштыргысыз, ял сәгатьләрендә дә...

– Бәлки, шулайдыр да, – дип җавап бирә ишәк. – Әмма вакыт узу белән, сезне машиналар кысрыклап чыгарачак һәм сездән хатирә генә калачак. Ә менә ишәкләрнең мәңге дә бетәсе юк...

• • •

Су кызы әтисе янына йөзеп килә:

– Әти, әле генә бер яхшылык эшләдем. Кешеләр ниндидер бер хайванны бау белән бәйләп су төбенә ыргыттылар, ә мин ул бауны кисеп ташладым. Яшәсен әйдә иректә.

– Әйбәт булган, кызым. Ләкин бүтән алай эшләмә.

– Ник?

– Чөнки ул хайван түгел, ә водолаз иде...

• • •

Убырлы карчык – аждаһага:

– Син нигә бик кәефсез әле?

Аждаһа:

– Нәрсәгә шатланырга соң? Башым – өчәү, ә пенсиям – бер генә...

• • •

Ике куян очраша. Берсенең сырты җәрәхәтләнгән.

– Аудамы?

– Ауда.

– Аучымы?

– Аттымы?

– Өскә басты...

• • •

Доктор Айболик ун сәгать буе черкигә үтә катлаулы микрохирургия операциясе ясый.

– Булды бу! Оч, нәни Черкием, һәм бүтән канатыңны сындырма!

Бер минуттан үзенең битенә чәпеп куя:

– Вәт, тиктормас бөҗәк!



Машина-тамаша

Татарстан Конституция советы Казан хакимиятенә социаль әһәмиятле объектлар — мәктәпләр, балалар бакчалары, медицина учреждениеләре белән янәшә урнашкан парковкаларда түләүне гамәлдән чыгарырга тәкъдим ясады. Шәһәр хуҗалары үз вариантларын тәкъдим итте: парковка түләүсез була ала, ләкин 30 минут дәвамында гына. "Баланы алып чыгарлык йә поликлиникага кереп чыгарлык вакыт аралыгында", – дип аңлатты шәһәр башлыгы Илсур Метшин. Башкача булуы мөмкин дә түгел, 30 минут эчендә безнең социаль учреждениеләрдә әллә нәрсәләр эшләргә була бит...

Дәүләт Думасы депутатлары Конституция судына 2024 елның декабрендә кабул ителгән юл хәрәкәте кагыйдәләрен бозган өчен штрафларны күтәрү хакындагы законның төп законга туры килмәве турында хат җибәргәннәр.Документ авторлары фикеренчә, хөкүмәт җаваплылыкны көчәйтүгә акча аз җыела башланганга күрә барган. Машина йөртүчеләр кагыйдәләрне сирәгрәк боза башлаган, штрафлар суммасы кимегән, шуңа күрә хакимият керми калган акчаны компенсацияләү максатыннан эшләгән.

Штраф җыю тармагы үз эшен дәвам итә. Хөкүмәт 12 яшькәчә балаларны креслосыз йөрткән өчен, штрафларны арттыруны хуплады. Закон проекты мондый суммаларны күздә тотып, гади машина йөртүчеләр өчен – 3 тән 5 меңгә кадәр, вазыйфага билгеләнгән затлар өчен – 25 тән 50 меңгә кадәр, юридик затлар өчен – 100 дән 200 мең сумга кадәр. Әйдәгез, барыбыз да кресло алырга!

Автомәктәпләр хәзер аны тәмамлаган кешеләр китереп чыгарган юл вакыйгалары саны буенча бәяләнәчәк. Аварияләр никадәр кимрәк булса, мәктәпнең рейтингы югарырак. Хөкүмәттә бу чара укыту сыйфатын күтәрәчәк һәм юлларда иминлекне яхшыртачак, дип уйлыйлар. Бик ышанасы килә...

Байлар да елый икән! Мошенниклар кармагына бер миллиардер капкан. Ул Mercedes-AMG One моделе алу өчен алдан ук аның тулы бәясен – 5,4 миллион доллар түләп куйган. Ләкин шома автодилер юкка чыккан, ә бизнесмен "тимер ат"сыз калган. Алдау тәртибе турында соңыннан гына тикшерүчеләрдән белгән.

Валерий ТАРАСЕНКО



Никифор ТУКМАЧЁВ

ЮЛЛАР-ЮЛЛАР

Юллар белән гел сөйләшеп йөрим,
Алар хәлен аңлыйм мин үзем.
Юллар-юллар инде ничә еллар
Ремонт күргәнегез юк сезнең...

Башлар төзәтергә китәдерме
Юллар төзәтәсе акчалар?..
Гаҗәп түгел инде җәяүлегә
Йөргән саен салым салсалар.

Җанны юатсак та җырлый-җырлый
Юлда йөрүләрне мактап без,
Юл газабы, гүр газабы, диләр
Йөрибезме шуны аклап без?

Язга чыккач тагын юл ямарлар
Безнең эшчеләрме, читләрме?
Ямау салып кемнәр яңарталган
Тишек-тошык иске чикмәнне?..

Авыр булса булсын дип җырлыйлар,
Кабул булды җырчы теләге.
Авырлыклар юлда гына түгел
Башка авырлыклар күп әле...

Анастасия ВАСИЛЬЕВА



Виктор БОГОРАД



Валерий ТАРАСЕНКО



Владимир СОЛДАТОВ



Евгений БУГРОВ

Гипноз көче

Күршемне очраттым, шундый шат, сөйли дә сөйли. Директорлары комбинатта коллектив өчен бәйрәм оештырырга уйлаган. Җитәкчелек итүенә 10 ел үткән икән һәм тантаналы кичәсенә концерт оештырып, гипнозчы да чакырган.

Барысы да бик матур киенеп җыелганнар, йөзләре шатлык белән тулып, балкып тора... Тантаналы өлеше тәмамланып, концерт өлеше башлана, һәм гипнозчы сәхнәгә чыга, барыгызны да йоклата алам, ди. Безнең директор, бөтенесен гаҗәпкә калдырмак булып, атылып сәхнәгә чыга. Янәмәсе, моңа кадәр аны әле берәү дә йоклата алмаган. Чыннан да, аның йоклаганын беркайчан берәү дә күрмәгән: әнә күл кырыенда үзенә нинди зур сарай төзегән, туганнары да бик яхшы яши башлаган: машиналарына утырып чит ил курортларына баралар, балалары да шундагы университетларда укыйлар... Нәрсә сөйләп торырга инде: күреп торабыз бит...

Гипнозчы моңа:

– Алайса, минем янга менегез! – ди.

Без барыбыз да тынып калдык – кызык: йоклата алыр микән, дип. Ә бу – шундук! – биш минут та үтмәде күзен йомды!

Гипнозчы сораулар яудыра башлады, директорыбыз бөтен нәрсәсен дөресләп чәчәргә тотынды: ничек акцияләр сатып алган, акчаларын нинди җай белән чит илләрдәге счетларга күчергән, кемнәр белән бүлешкән һәм сәркатибе белән Мальдив утрауларында ничек типтергән... Бөтенесен: парольләрен, яшерен эшләрен, счётларының номерларын... әйтеп салган.

Гипнозчы, моның гаепләре күпкә китте дип уятмакчы да булган, ләкин залдагылар рөхсәт бирмичә: уятмагыз, әйтсен, бөтен дөресен ахырга чаклы сөйләсен, дигәннәр. Хәтта бөтенесен язып бару өчен комиссия дә төзегәннәр. Ә инде гипнозчы китмәсен дип, җыелышып, аңа түләү оештырганнар...

Менә икенче тәүлек инде директор һаман йоклый һәм барысын да сөйли. Ә бүген ул бөтен акцияләрен кире кайтарачагын әйтә, кешеләр алдында үзенең милкеннән баш тарта. Коллектив инде бер фикергә килде – күпмесен балалар бакчасына бирә, хастаханә белән мунча ясатырга нинди күләмдә... Комиссия составын киңәйтергә нәтиҗә чыгардылар, хәзер анда прокурор, депутат һәм полиция. Ун ел эчендә байтак байлык үзләштергән икән бит... Кайберәүләр югары даирәләрдәге түрәләргә гипноз сеансы үткәрергә кирәк дигән фикергә үк килделәр...

Иң төп нәтиҗә: директор эштән китәргә гариза язды һәм кешеләр алдында гафу үтенде.

Менә шулай! Берегез дә миңа гипноз тәэсир итми дип сөйләп йөрмәгез, дип искәртеп, сүзен тәмамлады шаян күршем.

Абау!

ИДАРӘ ИТҮЧЕ НАДАННАР

Ни өчен түрәләрнең кешеләрдән ерак торулары һәм кайвакыт акылсыз карарлар кабул итүләре, Түбән Новгород РАНХиГС филиалы – Идарә итү Институты директоры Александр Парамоновны кулга алынганнан соң ачыкланган. Институт хакимият, төбәкләр, төрле министрлыклар һәм ведомстволар өчен кадрлар әзерли. Монда ел саен 4 меңнән артык студент укый. Әмма, килеп чыкканча, бередә лекцияләргә, семинарларга бару бөтенләй кирәк түгел икән, акчага яхшы билгеләр алырга да мөмкин. Кайбер "студентлар", хәтта зачетларга акча сарыф итмичә, турыдан-туры диплом сатып алганнар. Бер нәрсә бәхәссез: төп бюрократик осталык – ришвәт алуны булачак менеджерлар практикада бик яхшы үзләштергәннәр.

КЫЗЫК ЙОЛА

Тверьдә яшәүчеләрне җирле җеназа агентлыгының рекламасы шаккаттырган. Телевидениедә, "Кешеләр монда җирләнү өчен Тверьгә күченәләр" лозунгы астында төшерелгән роликта яшьләр шат музыкага бииләр, мәрхүмгә елмаялар, дулкынланалар, аны соңгы юлга озатканда кул болгыйлар. Шәһәр халкы мондый "иҗатны" бүтән дөньяга күчкәннәрне мыскыллау дип саныйлар, ә күмү осталары оппонентларын кайгыны мәңгелек бутауда гаеплиләр. Бер сүз белән әйткәндә, Тверьне күрергә һәм үләргә!

РЕМОНТ ДРАМАСЫ

Чиләбе драма театрында күптән көтелгән ремонт өч ел дәвам иткән. "Мәдәният" милли проекты кысаларында Мелпомен гыйбадәтханәсен яңартуга ике миллиард сум акча тотылган. Ләкин күптән түгел монда беренче катның түшәме җимерелгән. Гүзәллекне белүчеләр зыян күрмәгән, театр техник сәбәпләр аркасында кабат ябылган, ремонт драмасында кем гаепле икәнлеген тикшерү комитеты тикшерәчәк.

САЙЛАУЧАН КӘЛӘШ


Яшь кытай хатыны торак проблемасын уникаль рәвештә чишкән. Ул өй сатып алган һәм 36 кияү тапкан. Әфәнделәр, хыялдагы хытын-кызны таптык, дип уйлап, аңа өйләнергә җыенганнар. Туй алдыннан "кәләш" алардан гаилә оясына инвестицияләр салуны сораган. Килешүләр тәмамлангач та, кыз кияүләрне блокировать иткән. Полиция бу эштә катнашмый, чөнки корбаннар акчаны үзләре биргән.












«НАЧАР» ПРОЦЕНТЛАР

Сәламәт кешеләр юк, тикшерү үтеп бетмәгәннәре генә була, дип шаярта табиблар үзләре. Ә Татарстанның Хисап палатасы мәгълүматлары буенча, андыйлар республика буенча начар анализдагы лейкоцитлар хәтле. Моның сәбәбе – медицина җиһазларының тузуы. Саннар белән әйтсәк, 62 процент тәшкил итә. Башкаларына караганда, ешрак гамма-камералар, ангиографлар һәм рентген аппаратлары яраксыз хәлгә ешрак килә икән. 45 дәвалау учреждениеләрендә аудиторлар өч йөзгә якын җиһазның ремонтта булуы һәм техник төзексезлеге аркасында тик тору очракларына тап булганнар. Сәламәтлек саклау министрлыгында, аклану йөзеннән, ул аппаратларның күбесе гамәлдән чыгаруга күптән әзер, дип аңлата. Әмма бу бит клизма кую гына түгел – озак һәм газаплы процесс! Менә шуннан "начар" процент барлыкка килгән дә инде. Әмма, чиновниклар белдерүенчә, быелдан алып бу хәл уңайлана башларга тиеш. Медицина техникасын яңарту өчен инде суммалар каралган, заявкалар булдырылган. Ярый, тикшеренүләрне көтеп карыйк, аңа кадәр яши алсак, әлбәттә.

Сергей КОКАРЕВ









Евгений ОБУХОВ

ҮКСҮ һӘМ ЕЛАУ ДИВАРЫ

Дивар артында күршеләрнең баласы елый. Ядрыкин ачуы чыгып телевизорның тавышын ача төште.

– Ну, туйдырдылар! – диде ул танышы Гәрәйгә.

– Аптырама, – дип җавап кайтарды тегесе, телевизордагы программаларны тиз-тиз генә күчереп. – Үсә төшкәч тынычланыр.

Бервакыт Ядрыкин иртүк уянып китте. Вика да уянды. Бәлки, ул Лена булгандыр... Ядрыкин төгәл исенә төшерә алмады.

– Син нәрсә? – дип сорады Вика-Лена.

– Әнә кара...

Дивар артында кемдер паркет буйлап уенчык машинасын дерелдәтеп йөртә, җитмәсә, идәнгә кубикларын ыргыта. Шуннан соң нәрсәдер шапылдады да, елау тавышы башланды.

– Ай-яй, интектерәләр! – дип куйды Ядрыкин. Вика-Лена сәгатенә карады да китәргә җыенды.

Ә берчакны шулай, Ядрыкин рюмкага бүлгәндә, дивар артында ату тавышлары яңгырады.

Аңа килгән кунакның куллары калтырарга тотынды, ул чайкалып китте.

– Ах, син аны! – дип ухылдады кунак.

– Әйтмә дә инде, җанга тиделәр инде, – диде Ядрыкин. – Имтиханнарга әзерләнәсе урынга, ул әнә видеолар әйләндереп утыра.

– Түз инде, – диде кунак, рюмканы тутырып. – Укып, акыл кергәч рәткә керер.


Ә шулай көннәрнең берендә Ядрыкин эшеннән кайтты да сменасыннан соң ял итеп алырга уйлады. Кинәт шул чакны дивар артында сабый бала елаган көчле тавыш ишетелде. Ядрыкин бүлмәләрен карап чыкты. Телевизор астындагы лицензияләнгән иске дисклар өеме тузанга батканын күреп тынып калды. Телевизор үзе салфетка төсле шарф белән капланган. Күрәсең, кайчандыр Вика-Лена шулай иткән булгандыр. Ә чит ил шешәсенә утырткан узган елгы тополь ботагы шиңеп беткән...

Дивар артындагы бала һаман үкерә-үкерә елый...

Ядрыкин тыныч кына диварга килеп маңгае белән обойга терәлде һәм тавыш чыгармый гына елый башлады.







Виталий ВЕСНИН

Гадәти хәл

Бу хәл шәһәр тирәсендә генә йөри торган электричкада булды. Хәзер ничектер, белмим, элек, минем әле студент чакта, электричкаларда акча түләмичә хәйләләп йөрү гадәте бар иде. Кайберәүләр, вагон буйлап контролёр килгәнен күрү белән, электричканың соңгы вагонына йөгереп чыгып, билетсыз баралар иде.

Мин дә гөнаһсыз түгел, шундый ысул белән акчамны янга калдыргаладым. Студент вакыт бит, акчага такыр чак. Менә бервакыт, инде университетны тәмамлаган чагым, әбием янына барырга туры килде электричкада. Мин инде ул вакытта акчага бигүк мохтаҗлык кичерми идем. Билет алдым да тыныч күңел белән вагонга кереп утырдым һәм йоклап киткәнмен.

Ниндидер шау-шудан уянып китсәм: яшьләр, урыннарыннан капылт куптылар да, электричканың соңгы вагонына элдерделәр. Шул аңлашылмаучылыкта, онытылып, биштәремне алдым да шулар белән йөгердем. Аннан соң, элеккеге кебек, беренче вагонга күчтек. Әмма монда безне сюрприз көтә иде – икенче контролёр. Әлбәттә, алар бит инде билетсызларның барлык хәйләләрен беләләр һәм шуңа күрә һәрвакыт камап алу тактикасы оештыралар иде. Һәм менә тикшерү эшләре башланды: кемгәдер штраф салдылар, кемнәрнедер поезддан төшереп калдырдылар... Ниһаять контролёр минем янга килеп җитте дә мыскыллабрак сорады:

– Ну, дускай, билетыгызны күрсәтегез!

Мин кесәмнән билетымны чыгарып, тыныч кына аңа суздым. Ул берни аңламагандай, билетны әйләндергәләп карады да кабат миңа биреп, уйчан сорау юллады:

– Ә нигә бездән качтыгыз соң?

Хәзер миңа уйланырга чират җитте:

– Гадәткә кергән! – дидем мин ниһаять, дөрес җай табуыма сөенеп.

Сергей СОКОЛОВ





Сергей КОКАРЕВ

Алмаз ХӘМЗИН

ПАГАНИНИ, СТРАДИВАРИ ҺӘМ БЕЗНЕҢ СӘХБИ


Безнең Ташлык авылында гаҗәеп сокланырлык кеше бар иде – ул Сәхби абый. Кулыннан нинди генә эш килми аның – ярты авыл кешесенең тәрәзә наличниклары аныкыдыр. Өйләрнең тышын сырлау-ясау, капкаларны бизәү дисеңме – оста инде бар нәрсәгә. Балта остасы да, койма, рәшәткә корырга да – ни теләсә шул – Сәхбинеке шәп. Ясаган әйберләренең җылысы-нуры бар. Байтак еллар укытучы булып эшләве дә игътибарга лаек – учител Сәхбинең.

Болар гына түгел, әле аның хикмәтләре... Ул үзе ясаган скрипкасы белән дә бөтен кешене шаккаттырды. Ясау гына түгел, шунда уйнап сихерли дә иде бит кеше күңелен. Үзебезгә генә түгел, башка тирә-юнь авылларында уйнап күрсәтеп йөргәне булгалады – исләре китә халыкның шул скрипкәсендә ат кылында тарттырылган смычогын әрле-бирле тартып утырганына. Скрипкәсенең кылы профессионалларныкы кебек өчәү булды микән, анысын хәтерләмим, бергәләп концерт куеп йөрсәк тә. Паганини кебек уйный иде бер-ике кылы өзелсә дә – бер дә ким түгел. Ләкин ул скрипкәсен ияк астына куеп түгел, ә тез өстенә куеп, виолончельдәге сыман итеп уйный иде.


Сәхнәгә чыкса, сөйләнә-сөйләнә, скрипкасын көйгә кора, кылларын чиртеп, уйныйсы көенә җайлый. Үзе Паганини турында кызыклар сөйли: "Бер тапкыр, ди, аның аягы бик каты авыртып, аксап сәхнәгә чыккан. Тамашачылар аның бу рәвештә чыгуын эчләре катып, бот чаба-чаба көлеп каршылаганнар."Бервакыт аның алдындагы ноталарын яктыртырга кабызып куелган шәме сүнгән", – дип әйтүе булды, безнең концертта да электр лампочкасы шартлап, ут сүнде. Сәхабетдин абый, уйнавыннан туктамыйча "Тәфтиләү" көен суза бирде. Залда да алкышлар көчәйде. Ул һәвәсләнеп, атаклы гитара ясаучы Страдивари турында сөйләргә тотынды: "Скрипкә ул татарча "чыелдык" дигән мәгънәне аңлата". Итальянча аның исеме шуны белдерәдерме, миңа мәгълүм түгел. Әмма залдагы халык, аның бу сүзен хуплап кабул итте, күрәсең – кул чабуларын көчәйтеп алдылар. Шул чагында клуб хезмәткәрләре аның каршына куыклы лампа кабызып китереп утырттылар. Сәхабетдин абзыебыз көйли-суза сөйли-сөйли: "Аның ясаган скрипкаларының яңгырашлары хәзергә хәтле тиңдәшсез!" – диде. Әлегә хәтле аның скрипкалары ничек ясалган – тирән сер булып саклана. Уйлыйлар: барлык сер скрипканы каплаган лакта түгел микән, диләр. Алай гына түгел, шуны ясаган мастерскойның тузаны һәм шундагы вак-төяк бөҗәкләрнең канатлары булырга да мөмкин икәнлегеннән шикләнәләр. Икенче төр фикер дә яши – ул яктагы агачларның сумаласын да катнаштырмадылар микән дип уйлыйлар. Хәзер инде ул тәҗрибәне кулланып булмый икән, чөнки андый урманнар киселеп беткән.

Менә шушындый хәлләр турында сөйләп, Сәхабетдин абзыебыз, безнең халыкта искитәрлеге булмаган скрипка дәрәҗәсен күтәреп, үзенең абруен үстереп, сәхнәдә тыйнак кына чыгыш ясап, олы яшьтә булуына карамастан, безнең белән концертлар куеп йөри иде.

Борис СТАРЧИКОВ, 1977 ел.



Герман ОГОРОДНИКОВ, 1994 ел.



– Котлыйм! Сез уйлап чыгарган әйбер кабул ителде. Без аны чит ил фирмасыннан сатып алган идек инде!



• • •

– Нигә әле бик күңелсез?

– Бик яхшы кешегә кияүгә чыктым. Ул мине хөрмәт итә. Минем теләсә нинди теләгемне үти.

– Шуннан?!

– Менә шуңа нинди дә булса җәнҗал куптарырга сәбәп таба алмыйм.

• • •

– Бигрәк оятсызландылар бу курьерлар, скутерларында тротуардан йөриләр, – дип сукранды бер карчык, урам аша шосседан кызыл утка чыкканда.

• • •

Катлаулы чорда яшибез. Бай кешеләргә, чит илгә акча күчерергә, шуны мошенникларга алдаганнары өчен бирергә туры килә.

• • •

Ир кеше төнге каравылчы булып эшкә урнашмакчы була. Аның белән сөйләшү бара:

– Бу эшкә без теләсә кемне ала алмыйбыз. Бу урынга туры килерлек нинди сыйфатларыгыз бар?

– Бар. Мин бик сизгер йоклыйм.

• • •

“Үзегезне үзегез дәваламагыз” һәм “Терапевтка язылу ике ай алдан” дигән ике фразага аптыраудан һич арымам.

• • •

– Ябыгырга булдым. Фитнеска язылдым, бассейнга һәм хорга.

– Ә нигә хорга?

– Аерма юк, ашарга гына вакыт калмасын!

• • •

– Кадерлем, син буянырга оныттың.

– Борчылма, куркыныч түгел!

– Син моңа үзең ничек карыйсың...

• • •

Ике иске таныш очраша:

– Кыяр күк күренәсең!

– Ничек кенә әле! Мин бит банкта эшлим.

• • •

– Һәр товарга сатып алучы табып буламы?


– Әлбәттә!


– Менә, мәсәлән, бер капчыгымда күгәреп, кәкрәеп беткән кадакларым бар, шуларны нишләтергә?

– Соң сезнең янда машина тәгәрмәче шиналарын төзәтә торган мастерской юкмыни?

Рәссамнар турында...









КИРӘКЛЕ КИҢӘШ

Хөрмәтле редакция! Укырга беркайчан да соң түгел, диләр, ләкин... Менә инде ничә еллар безнең бистәдә яңа мәктәп төзергә вәгъдә итәләр, аңа җир дә бүленеп бирелгән һәм төзи башлау вакытлары да мәгълүм иде – 2023 ел. Әмма бу эш әле быел гына башланды, көтмәгәндә. Иске мәктәп бинасына терәп, өстәп кенә киңәйтү чаралары үткәрергә керештеләр – шулай иткәч, уку-укыту эшләре җиңеләячәк, янәмәсе. Шуның өчен хәтта балаларның спорт мәйданчыгына да тыгылдылар. Әмма болай итеп тә балаларга урын җитмәячәге көн кебек ачык. Хәзер алар бистәдә 1300 ләп, ә монысы бары тик 600 балага гына җитәрлек. Бу мәсьәләгә җавап анык – яңа мәктәп төземичә генә шырды-бырды төзеп, педагогик җитешсезлекләрдән котылып булмаячак.

Яңа Сокуры бистәсе халкы

ЛАЕШ районы


КОЙМАЛЫ ЧИТЛЕК

Кадерле "Чаян"! Казанның истәлекле урыннарының берсе – юл колеяларыннан башка, юл кырыендагы тимер киртәләр. Аларны күпләп кую юл хәрәкәте куркынычсызлыгын саклау ниятеннән, берничә ел элек башланган иде. Шуннан соң бу башлангычны бөтен шәһәр буенча эләктереп алдылар. Хәзер инде эш ишегалды мәйданнарына да күчте. Бу хәл, күнегелгән гадәти юл булып, Горсовет урамындагы 29 нчы йорт белән Аркылы-Базар урамы 61 нче йортны коймалап куйды. Шәхси милекне теләсә нинди үтеп йөрүчеләрдән аердылар. Шулай итеп, кибетләргә, тукталышларга алып баручы "халык сукмагын" кистеләр. Инде ул җирләргә барып җитәр өчен әллә кайлардан әйләнеп йөрергә кирәк. Ирексездән уйлап куясың: әгәр дә мондый коймалар кору алга таба да киң җәелә башласа, бер матур көнне үзеңнең камалган ишегалдыңнан чыгып, күршедәге коймалы читлеккә эләкмәм дип кем әйтер...


Э. Курамшин

КАЗАН


ЯЗГЫ ҖИЛЛӘР



Игорь КИЙКО



Максим СМАГИН



Күренекле шагыйрь Роберт Вәли улы Әхмәтҗанов 1935 елның 1 апрелендә Татарстанның Балык Бистәсе районы үзәгендә туа. Робертның бала чагы һәм үсмер еллары шул районның Иске Арыш авылында уза. 1954–1959 елларда Казан дәүләт педагогия институтының татар теле һәм әдәбияты бүлегендә укый. Студентлык чорында җитди рәвештә әдәби иҗат эше белән шөгыльләнә, ә 1958 елда инде Татарстан китап нәшриятында студент егетнең «Беренче яз» исемле тәүге шигъри җыентыгы дөнья күрә.

1959–1960 елларда Р. Әхмәтҗанов Әстерхан өлкәсендә татар теле һәм әдәбияты укытучысы булып эшли. Казанга кайткач, Татар дәүләт опера һәм балет театрында әдәби бүлек мөдире (1961–1962) булып эшли. Шул ук вакытта «Татарстан яшьләре», «Социалистик Татарстан» (хәзерге «Ватаным Татарстан»), «Яңа аваз», «Заман-Татарстан», «Шәһри Казан» газеталарында әдәби хезмәткәр вазыйфаларын башкара.

Р. Әхмәтҗанов – татар поэзиясендә үзенә генә хас шигъри йөзе, язу стиле булган талантлы шагыйрьләрнең берсе. Шигъри форма өлкәсендәге эзләнүләрнең нәтиҗәсе буларак, татар поэзиясендә «Йолдызстан», «Таш аргамак», «Уйна, улым!», «Сәхипҗамал» кебек яңа поэмалар мәйданга килә.

Шагыйрь татар поэзиясендә баллада жанрын үстерүгә шактый өлеш кертә («Таш елады», «Гармун турында баллада», «Яралы арыслан» һ.б.). Шагыйрь ритм нечкәлеген оста тоя, әсәрнең музыкаль яңгырашына зур игътибар бирә. Бу сыйфатлар, күрәсең, композиторларга да илһам чыганагы булып хезмәт итәдер.

Халыкка мәгълүм җырлардан «Саумы, кояш!» (М. Мозаффаров музыкасы), «Солдатлар» (Ф. Әхмәдиев музыкасы), «Кояшларың белән кил син миңа» (А. Монасыйпов музыкасы), «Синең эзләр» (Р. Еникиев музыкасы), «Минутларны ник саныйсың» (З. Гыйбадуллин музыкасы) кебек җырлар татар музыка хәзинәсенең кыйммәтле бер өлешен тәшкил итәләр.

Роберт Әхмәтҗанов – 1965 елдан СССР (Татарстан) Язучылар берлеге әгъзасы.

1958–2005 еллар арасында Р. Әхмәтҗановның лирик шигырьләре, поэма һәм балладалары тупланган ике дистәгә якын китабы дөнья күрә. Татарстан китап нәшриятында басылган «Тургай тәрәзәсе» (1995) һәм «Мәгариф» нәшриятында нәшер ителгән «Кичке кошлар» (1999) исемле китаплары өчен Р. Әхмәтҗанов 2001 елны Татарстан Республикасының Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә лаек була. 1995 елдан «Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе» дигән мактаулы исем йөртә.

Шагыйрь 2008 елның 13 маенда Казанда вафат була.

КЫРЛАРЫМДА, ӘНКӘЙ, ИМИНЛЕКМЕ...

Кырларымда, әнкәй, иминлекме,
Агарамы борчак басулары?..
Тәрбелидә йөргән торналарым
Кайтты микән быел? Барсыдамы?

Керләреңне, әни, җил аламы?
Тәрәзәңдә миләш чайкаламы?
Каз үләнле чишмә сукмагына
чиләгеңнән сагыш чайпаламы?

Камылларга тулган зәңгәр таңмы,
кызардымы яфрак өрәңгедә?
Сибәлиме спас яңгырлары
Бәрәңгегә?

Капкаң бик еш ачылып ябыламы,
кояшлымы һаман ишек алды?..
Әңгер төшкәч, карт-корылар гаме
биләп ала микән күрше тауны?..

Мин тау чаклы сорау өеп, тагы
онытканмын, әни:
үзең саумы?!

Иминлекме, әни, йөрәгеңдә?!

СИН КИЛГӘН ЮЛЛАР

Син килгән юлларда – яз бүген,
Күгәрчен юынып кагынган;
Кояшны аз гына шәүләләп,
Иң якты болытлар агылган...

Синең як, синең җыр! Үзеңдәй
Назлана кыргый кыр гөлләре;
Яз керсә, исемеңне сагынып,
Мөлдери мәхәббәт күлләре!..

Тургайлар шатланган һавада
Безнең дә шатлыкка урын бар.
Яз керсә, син килгән эзләргә
Яшәреп гөл чигә болыннар.

Син килгән юлларда – яз бүген,
Күгәрчен канаты кагылган...
Яз булып син килгән юлларда
Иң якты җырым бит табылган!..



СОЛДАТЛАР

Фәтхерахман Әхмәдиев көе

Озатып вокзаллар каршында
Маңгайдан үптеләр аналар.
Тузанлы юллардан үттеләр
Дөньяны күрмәгән балалар.

Балалар керделәр утларга,
Балалар сүз бирде тупларга.
Күпләре, төренеп шинельгә,
Калдылар еракта йокларга.

«Балалар, торыгыз, балалар,
Ашыгыз суына табында...»
Ничә ел тормыйлар балалар
Иделдә һәм Дунай ярында...

Уятма, йокласын, син, ана,
Айларны, елларны санап бар:
Күңелдә һаман яшь, гел бала –
Кайтмаган солдатлар, солдатлар.

Ана ул йокламый, сабые
Юрганын ачса да уяна.
Аналар йөрәге шикелле
Мәйданда мәңгелек ут яна.

Аналар йөрәге шикелле
Ут яна, уйлана, талпына.
Аналар хәтере шикелле
Җил йөри курганнар артында.

ШИГЫРЬ ИЛЕ

Сүзеңне сал вакыт арасына, –
иркен итеп алсын ул тынын...
Аккан су да сиңа: «бер!» дигәндә,
ике тапкыр какмый дулкынын!

Каләмең дә канатланган сыман,
шигыреңдә һәр сүз суласа!..
Сүзләр елый, алар тончыгалар,
вакыт аралыгы булмаса...

Тезелеп калсын иҗат түтәлләрең,
Чәчәкләнсен Шигырь илеңдә!
Затлы орлык сыман сикереп төшәр
тере сүзләр булсын телеңдә!

Ак кәгазьгә төшеп, йөгереп китсен,
Зур иҗатка илтсен эзләре.
Бер җөмләдә килеп очрашсыннар
«Сөям!» белән «сине» сүзләре...

Һава калдыр, сулыш калдыр сүзгә, –
тылсым уты янсын шигырьдә!
Мәхәббәтең сал да шул юлларга,
һич чыкмаслык итеп сихерлә!..

Вакыт-вакыт рухың килеп чыкса,
галәмнәрдән килгән авазга,
ал син аны, шагыйрь, йөрәк тавышың
язылып калсын
ап-ак кәгазьгә!

Гүзәл СӨНГАТУЛЛИНА

Диета

Яз гадәттәгечә көтелмәгәндә килеп җитте. Ул көзге каршына басып үзенә карады... Аннан үлчәүгә басты да таң калды: абау, озакламый җәй, җылы көннәр җитә. Ә ул... кыскасы, ашыгыч хәлдә диетага утырырга кирәклеген аңлады.

Аңлавы бер эш, ләкин ничек шул диетаны тотарга?

– Кадерлем, – ди иренә, – әйдә, иртәгәдән файдалы ризыклар гына ашыйбыз, диетага утырабыз.

– Ни булды тагын сиңа? – дип аптырады ире.

– Ничек, ни булды? Син миңа кара... Үзең дә әйтмисең, бераз ашамый тор диеп. Җәйге киемнәремә сыймый башлаганмын.

– Әһә, син сыймыйсың, ә диета икебезгә?

– Соң, ашарга мин пешерәм түгелме? Үземә бер ризык, сиңа икенчесен пешереп мин ничек ашамыйча түзәргә тиеш ди?

Чынлап та, хәзер кибеткә керү белән нинди генә тәмле ризыклар сатылмый. Сөткә дип керсәң, торт сатып аласың. Йә тагын берәр тәмле нәрсә.

Хатын бик якын дустын исенә төшерде. Ул бик тә нәфис гәүдәле, чибәр. Нинди диетада утыра икән? Аңа шалтыратырга булды.

– Дустым, – ди, – син нинди диетада утырасың? Миңа да әйт әле шуны. Җәйге киемнәремә сыймый башлаганмын. Озакламый җәй җитә, без ирем белән курортка барырга дип планнар корган идек. Мондый кыяфәттә ул миңа карамас та, анда нечкә билле кызлар күп булыр.

– Юк ла инде, мин диетада утырмыйм, – дип җавап бирде дусты.

– Утырмыйсың? Шаяртма. Шундый нечкә билле булуың диетада булгангадыр.

– Юк, мин ит, май ашамыйм.

– Вегетарианкамы?

– Бюджетница. Безнең хезмәт хакы әллә ни күп булмаганга, мин андый ризыклар бик сирәк алам. Аннары, тортлар да, баллы ризык та ашамыйм.

Кичен, ире эштән кайту белән хатыны сүз башлады:

– Менә нәрсә, җанкисәгем, әниләреңә шалтыратып әйт, авылдан итләр, майлар, китермәсеннәр. Бераз яшелчәләр, боткалар ашаштырырбыз. Икебезгә дә файдасы булыр.

– Кадерлем, мин дә көне буе син әйткән сүзләр турында уйладым. Нигә кирәк сиңа ул диета? Син бит минем шундый матур. Киемнәрең ярамаса, яңасын алырбыз. Анысы зур проблема түгел.

– Яхшы, алай булгач, иртәгә үк кибеткә барып яңа киемнәр алырбыз.

Ире сөенеп ризалашты. Чөнки кием белән генә котылды. Ә диета мәшәкате озаккарак сузылган булыр иде.

Рәфкать ИБРАҺИМ

ПАТРИОТ

Патриотлыкка өндиләр
Илебез башлыклары,
Шул чагында арта икән
Тормышның шатлыклары.

Патриот булып карадым,
Ләкин мәгънә күрмәдем,
Олигархны яклауда
Алга китеш сизмәдем.

Патриотлыкка хас түгел –
Чит җирдә байлыкларың.
Ул илләрдә белем алган
Балалар, оныкларың.

Телем киселгән илемдә
Мин патриот булалмыйм,
Хокуксызлыкта яшәүне
Һич тә кабул италмыйм.

Дәүләт төзүче – бер милләт!
Калганнары саналмый.
Хокукы чикләнгән халык
Патриот була алмый.

Илнең барлык халыклары
Патриот булсын иде,
Тигезлектә, бердәмлектә
Яшәргә язсын иде.

• • •

– Официант, сез миңа нәрсә китердегез?

– Бу диетик аш.

– Чынлапмы? Мин гомерем буе диңгезче булып суда йөздем, әмма шушы яшемә җитеп, диетик аш дулкыннарын ярып йөргәнемне белмәгәнмен икән.



Ринат АБЗАЛОВ



ЧАЯН
САТИРА ҺӘМ ЮМОР ЖУРНАЛЫ
1923 елдан чыга.
№ 4 (1953) апрель 2025

Баш редактор:
Р. И. ХӘЛИЛУЛЛОВ
Баш рәссам: А. АЛЁШИН
Баш редактор урынбасары: Г. ЗАМАЛДЫНОВА
Редакторлар: Р. АБЗАЛОВ, Л. САФИУЛЛИНА, А. ХӘМЗИН
Сайт редакторы: Л. ӘХМӘТОВА
Корреспондент: Г. СӨНГАТУЛЛИНА
Дизайнер: Л. ФӘЛӘХОВА

Учредителе һәм нәшер итүчесе «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыяте.
420047, Татарстан Республикасы, Казан, Академическая урамы, 2
Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләре агентлыгы ярдәмендә оештырылган.
Журнал Роскомнадзор идарәсендә теркәлде.
Теркәлү саны һәм вакыты: ПИ № ФС77-44364, 23 март, 2011 ел.
«Журналга «Почта России» каталогы, йә https://podpiska.pochta.ru онлайн аша языла алалар.

Язылу индекслары:
РТ – П2438 (тат), П2440 (рус);
РФ – П7088 (тат), П7087 (рус).
Редакция материалларны авторларның ризалыгыннан башка редакцияләү-төзәтү хокукына ия.
«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» типографиясендә басылды.
420066, Татарстан Республикасы, Казан, Декабристлар ур., 2.
Чыгу көне: 01.04.2025 ел.
Тираж – 1596 Заказ М-0539
Редакциянең адресы: 420066, Татарстан Республикасы, Казан, Декабристлар ур., 2.
Белешмәләр өчен телефоннар: (843) 222-06-00, 222-05-54.
E-mail: chayan@bk.ru
Сайт: chayan-journal.ru
Бәясе ирекле
16+

Уйна да, уйла да!

Ринат АБЗАЛОВ төзеде.

ГӨЛСЕМ ... | "... ӘЛЕ УРМАННАРГА" | "... ӨЗМӘ ГЕНӘ" | "ТОТ, ...(-1)НЕ, ТОТ ТУРЫ" | БИЮ КӨЕ | НОТА | ... САТИЕВ | ШАГЫЙРЬ ... КАСЫЙМОВ | МӨСЕЛМАН ИЛЛӘРЕНДӘ МИНИСТР | ... ИТЕК | БАЯНЧЫ ... КУРАМШИН | ПУШКА | "... ИРКӘМ, ... ИНДЕ" | "... УРМАН" | "... КАНАТЫ АТ БУЛА" | ҺӨҖҮМ АВАЗЫ | ТУГАН ... | "ИРТӘНГЕ ..." | "ТИК БЕР ГЕНӘ ..." | ӨЕЛГӘН УТЫН | КИРӘК -ЯРАК | ХЕЗМӘТ ХАКЫНЫҢ ӨЛЕШЕ | ТӘРҖЕМӘЧЕ ... ИБРАҺИМОВА | ЖЫРЧЫ ... НУРГАЛИЕВ | НОТА | АЗИЯДӘГЕ ДӘҮЛӘТ | "АГЫЙДЕЛДӘ ИКЕ ..." | СЫЕР АВАЗЫ | НОТА | СКРИПКАЧЫ ... ЗАКИРОВА | ИРАННЫҢ АКЧА БЕРӘМЛЕГЕ | "(-1)... КУЛЫННЫ, ГҮЗӘЛЕМ" | АСЫЛТАШ | ШӨҺРӘТ(-1) | "... БУЕ – ТУГАН ЯК" | ТАРТТЫРЫЛГАН ЯРМА | "ӘКРЕН КИРӘК, ...ЛӘП КИРӘК..." | ХАТЫН-КЫЗНЫҢ БАШ КИЕМЕ | "ҮСЕП УТЫРА БЕР КАРТ (-1)..." | ЯШЬ КИЛЕН | КОМПОЗИТОР ... ХӨСӘЕНОВ | ... ЛЕРОН | "СУТЫЙ" | "КАРМАК САЛА ...!"



1. Кафеда очрашу өчен кем туләргә тиеш?
2. Эш урынының озак вакыт буш булып торуы нәрсәне аңлата?
3. Мәңгелек мәхәббәтнең ышанычлы вакыты?
4. Нәрсә ул ялгызлык?
5. Хатын-кыз хуҗалыгы өчен иң файдалы әйбер?
6. Күренекле һәм танылган кешеләр арасында аерма?
7. Картлыкта ирле-хатынлы мөнәсәбәт ничек үтәлә?

ҖАВАПЛАР

1. Кафеда очрашулар өчен дәүләт түләргә тиеш, чөнки барысыннан да бигрәк ул кызыксына гаилә төзү мәсьәләсендә, һәм балалар тудыру бурычы да аның өстендә булырга лаек. 2. Аз түлиләр яки урлар өчен бернәрсәләре дә юк. 3. Ширбәтле ай. 4. Мобильнигың дәшмәгәндә, ә будильнигың шалтырамаганда. 5. Гаепле ирең. 6. Беренчеләре үзләренең талантлары һәм хезмәтләре аркасында шундый булганнар, ә икенчеләре – дан казанасы килү аркасында. 7. Хатын иренең күзенә дару тамыза, ә ир хатынының сыртына ревматизмнан мазь сөртә.

Сынамышларны Гүзәл СӨНГАТУЛЛИНА әзерләде.

Чаянвордны чишегез, номерланган шакмакларда җыр исемен укыгыз. Журналыбызның 3 нче санында басылган чаянвордның тикшерү сүзе – **«ОНЫТА АЛМЫЙМ»**.


Беренче булып дөрес җавап җибәрделәр:

Р. ТУКМАНОВ (Казан),
С. ШӘЙХУЛЛА-ӘНӘЛЕ (Казан),
З. ЯРУЛЛИНА (Апас).

Җиңүчебез – Казаннан **Рөстәм ТУКМАНОВ!**

Сәер кешеләр

Виктор БОГОРАД



Сергей СОКОЛОВ



Вячеслав ШИЛОВ



Владимир ВАСИЛЬЕВ

